**ГЛАВА СОВЕТА**
**СОКУРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422622 с. Сокуры,
ул. Державина , д.12 а
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ районы СОКУРЫ АВЫЛ**
**ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

422622 Сокуры авылы,
Державино урамы, 12а нчы йорт,
тел: (факс) 8 84378 4-07-83
E-mail: Sokur.La@tatar.ru

---

**2026 елның 28 гыйнвары** **03 номер**

**КАРАР**

**«Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирлекләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1), Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Сокуры авыл җирлеге, Сокуры авылы, Достоевский урамы, 12 нче җир участогы адресы буенча урнашкан, 1387 кв. м мәйданлы, 16:24:240303:2328 кадастр номерлы җир участогыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төре — «биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү» буенча рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында..**

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, тирә-юнь мохитне саклау, территорияләрне планлаштыру өчен шартлар булдыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8 матдәсендәге 1 пункты, 30, 31, 32 матдәләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль канун, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирлекләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1), Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Сокуры авыл җирлеге, Сокуры авылы, Достоевский урамы, 12 нче җир участогы адресы буенча урнашкан, 1387 кв. м мәйданлы, 16:24:240303:2328 кадастр номерлы җир участогыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төре — «биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү» буенча рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Ачык тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты – 2026 елның 6 феврале, сәгать 14.00;

2.2. Үткәрү урыны – Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасы, адресы: ТР, Лаеш районы, Сокуры авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт;

2.3. Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирлекләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1), Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Сокуры авыл җирлеге, Сокуры авылы, Достоевский урамы, 12 нче җир участогы адресы буенча урнашкан, 1387 кв. м мәйданлы, 16:24:240303:2328 кадастр номерлы җир участогыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төре — «биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү» буенча рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукы белән катнашуга гаризалар бирү срогы – 2026 елның 26 мартына кадәр; язма рәвештә, көн саен эш көннәрендә сәгать 08.00дән 12.00гә кадәр, 13.00дән 16.00гә кадәр Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитетына (адрес: ТР, Лаеш районы, Сокуры авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт) тапшырыла.

Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелүе мәҗбүри:

- Гражданнар өчен: фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны буенча теркәлү адресы, эш урыны һәм биләгән вазыйфасы, контакт телефоннары;
- Гражданнар төркеме өчен: фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре, нинди дә булса җәмәгать оешмаларына яки берләшмәләренә каравы (булган очракта), яшәү урыны буенча теркәлү адреслары, контакт телефоннары;
- Юридик затлар өчен: оешма бланкында, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелеп.

2.4. Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлеге территориясендә урнашкан 16:24:240301:1777 кадастр номерлы җир участогы территориясен планлаштыру проектын раслау мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр мәгълүмат басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) вакыттан алып 2026 елның 26 мартына кадәр (шул көнне дә кертеп) язма рәвештә эш көннәрендә сәгать 08.00дән 12.00гә кадәр, 13.00дән 16.00гә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Лаеш районы, Сокуры авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт.

3. Сокуры авыл җирлеге Башкарма комитетына Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирлекләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге шәхси торак төзелеше зонасында (Ж1), Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Сокуры авыл җирлеге, Сокуры авылы, Достоевский урамы, 12 нче җир участогы адресы буенча урнашкан, 1387 кв. м мәйданлы, 16:24:240303:2328 кадастр номерлы җир участогыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төре — «биналарда спорт белән шөгыльләнүне тәэмин итү» буенча рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны оештыруны һәм үткәрүне, шулай ук гражданнарның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

3.1. РФ ГрК 5.1 маддәсендә каралган иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр әзерләргә.

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән соң 7 эш көненнән дә соңга калмыйча «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә әлеге карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрнамәне бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.3. РФ ГрК 39 статьясындагы 4 өлеше нигезендә әлеге рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләренең хокук ияләренә, әлеге рөхсәт сорала торган җир кишәрлеге белән уртак чикләре булган җир кишәрлекләрендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренә һәм әлеге рөхсәт сорала торган капиталь төзелеш объектының өлеше булган урыннарның хокук ияләренә гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәрләр җибәрергә.

4. Әлеге карарның 2 п. күрсәтелгән датада һәм вакытта гавами тыңлаулар уздырырга.

4.1. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү һәм раслау вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенең 4.2 пункты нигезендә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көннән алып ике эш көне эчендә Татарстан Республикасында җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә документлар комплекты белән хәбәр итәргә кирәк.

4.2. Гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне соңгы карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

5. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Сокуры**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.Р. Мәүлиев**